РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
КЛЯШЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ
ТЕТЮШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТӘТЕШ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЕЛӘШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

тел. (84373) 56-0-39, факс 56-0-39

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**16 .11. 2021** **№ 2**

**Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлегенең Тоншерма торак пунктында 2022 елда үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 ст., Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы «Келәш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 23 ст. нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тоншерма авылы, Ленин урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан Тоншерма авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 30 ноябрендә 9 сәгать 00 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Тоншерма Келәш авыл җирлеге торак пунктында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын билгеләргә.

2. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тоншерма авылы, Ленин урамы, 54 нче йорт адресы буенча урнашкан «Тоншерма урта гомуми белем бирү мәктәбе» МББУ бинасы янында 2021 елның 30 ноябрендә 10 сәгать 30 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Тоншерма Келәш авыл җирлеге торак пунктында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы, Тәтеш районы, Тоншерма авылы, Ленин урамы, 57 нче йорт адресы буенча урнашкан Тоншерма авыл мәдәният йорты бинасында 2021 елның 30 ноябрендә 12 сәгать 00 минутта, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Тоншерма Келәш авыл җирлеге торак пунктында 2022 елда үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының өченче этабын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге Тоншерма торак пунктында яшәүчеләр исемлеген сайлау тәртибе вакытлыча билгеләнгән.

5. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«2022 елда үзара салым кертүгә Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Келәш авыл җирлеге Тоншерма торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 1000 (бер мең) сум күләмендә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан тыш, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

- авыл эчендәге юлларны ремонтлау (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү); Чапаев урамы буенча 16-нчы номерлы йорттан Ленин урамы буенча 54-нче номерлы йортка кадәр.;

- Тоншерма торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (су башнясы янында павильон төзү: төзелеш материаллары сатып алу, эшләр, хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Тоншерма т. п. урнашкан буаны чистарту эшләрен башкару өчен проект-смета документациясен эшләү;

«КАРШЫ» “РИЗА”

6. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кeләш авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын оештырырга һәм үткәрергә.

7. Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кeләш авыл җирлеге башкарма комитеты Гражданнар җыенын үткәргәндә, Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кeләш авыл җирлеге территориясендә яңа коронавирус йогышы (COVID-19) белән авыру очракларын кисәтү һәм тарату өчен профилактик, санитар-эпидемиологик чараларның үтәлешен тәэмин итәргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районы Кeләш авыл җирлегенең мәгълүмати стендларында урнаштыру юлы белән Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга. https://tetushi.tatarstan.ru/

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

**Җитәкче** **Ф.Х. Галимов**